■ Хәзрәт вәгазе

# СӨТ ӘНИСЕ

Кадерле балалар! Сезгә изге Мәккә шәһәренең элекке тарихыннан бер хикәя сөйлибез.

Изге Мәккә шәһәрендә көннәр бик эссе торган. Җәйге кызу көннәрдә яңа туган балаларга анда яшәү бигрәк авыр булган. Шул сәбәпле, аларны Мәккәдән җәйләүләргә озата торган булалар. Аларны имезеп, тәрбияләп үстерүче хатыннарны сөт әниләре дип йөрткәннәр. Сөт әниләре, ел саен мәккәгә килеп, гаиләләрдән кечкенә бәбиләрне үстерергә алып киткәннәр.

Бәбиләрне таза-сау үстереп, кире әтиәниләренә кайтарганнар. Аның өчен күп акча, кыйммәтле бүләкләр алганнар.

Шундый сөт әниләренең берсе Хәлимә дә, ел саен Мәккәгә килгән.

Нурлы бала Мөхәммәд туган елны, Хәлимә, башка хатыннарга ияреп, янә Мәккәгә юл тота. Бу юлы аның белән ире Харис та бара. Харис Мәккәгә акча эшләү нияте белән килә. Чөнки ул елны артык кызудан игеннәр корган, чишмә сулары кипкән була.

Авыр тормышта яшәүче Харис белән Хәлиминең бер кәҗәләре була. Шуның сөтен савып, алар яңа туган бәбиләргә эчертәләр. Әммә коры елның авырлыгы мескен кәҗәгә дә төшә. Ашарына яшел үлән булмагач, хәлсезләнеп, сөт бирми башлый.

Барлык сөт әниләре кебек, Хәлимә дә, берәр бай гаиләнең баласын алып кайтырга өметләнә.

Харис белән Хәлимә көч-хәл белән Мәккәгә килеп җитәләр. Башка сөт әниләре бай гаиләләрдән бәбиләрне инде алып бетергән булалар.

Бөтен Мәккәгә бер генә бала кала. Ул да булса - ятим.

Бу бәбинең кем икәнен аңлагансыздыр инде, кадерле балалар?

Әйе, Нурлы бәбине, ятим булганга күрә, бер генә сөт әнисе дә алмый.

Хәлимә нәкъ менә шул Нурлы бәби торган йортның ишеген шакый. Аннан Габделмотталиб исемле кеше чыга.

Габделмотталиб, Хәлиминең имезергә бала эзләгәнен ишеткәч, бераз уйга кала.

Аннан:

- Әйе, минем бер оныгым бар, әмма аны бер генә сөт әнисе алырга теләмәде, - ди.

Хәлимә гаҗәпләнеп:

- Ни өчен, - дип сорый.

Габделмотталиб:

- Оныгым ятим. Өстәвенә, сөт әнисенә бирерлек акчабыз да, бүләкләребез дә юк, - дип җавап бирә.

Хәлиминең, билгеле, җәйләүгә бәбисез кайтасы килми. Әммә ярлы гаиләнең баласы белән нишләмәк кирәк,

- Ирем белән киңәшләшим, - дип китеп бара.

Базарда эш эзләп йөргән ирен очратып, Хәлимә хәлне аңлатып бирә.

Харис:

- Бала ятим, дисең, шулай булгач, гаиләсе ярлы булса да, алыйк без аны. Бәлки Аллаһ аның хөрмәтенә йортыбызга хәер-бәрәкәт индерер, - дип, үз фикерен әйтә.

Ә бу вакытта Габделмотталиб белән Әминә, тынгысызланып, Хәлиминә көтәләр. Нурлы бәбиебезне алырга ризалашырмы, - дип борчылалар.

Бераздан Хәлимә әйләнеп килә. Барысы да куана. Бергәләп нурлы ятим яткан бүлмәгә керәләр. Хәлимә, аны күрү белән, үз баласы кебек якын итә, ярата башлый.

- Бу нинди гүзәл, нинди нурлы бала! - дип, бәбине куенына ала.

Бала да, күзләрен ачып, Хәлимәгә елмаеп карый.

Хәлимә, дулкынланып:

- Борчылмагыз. Аны үз баламнан да яхшырак карармын, - ди.

Бәбинең газиз әнисе Әминә, бәгырь җимешеннән аерылганга, бераз моңсулана. Әммә аның та-асау үсүе өчен түзәргә кирәклеген аңлый.

Ул, мөлдерәмә тулган күз яшен туктата алмыйча, нурлы сабыен кочаклап, туйганчы иркәли.

Хәлимә, нурлы баланы куенына алып, кайтыр юлга чыга. Арыганын да, ашыйсы-эчәсе килүен дә оныта. Ни гаҗәп, талчыккан ишәккә дә яңа җан кергән кебек була.

"Бу балада ни дә булса бардыр", - дип уйлый эченнән генә Хәлимә. Үзе нурлы бәбине кат-кат үбә.

"Әле ярый Мәккәгә соңарып килгәнмен. Югыйса, өлешемә башка берәр сабый тигән булыр иде", - дип, язмышына рәхмәт әйтә.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Сәфәр 2011 миләди йыл**
**1432 һижри йыл.**

| Сәфәр, Рабиғөл әүүәл | Аҙна көндәре | Ғинуар-Февраль | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Кесе йома | 20 | 7.36 | 9.27 | 13.30 | 15.40 | 17.27 | 19.18 |
| 17 | Йома | 21 | 7.35 | 9.26 | 13.30 | 15.42 | 17.29 | 19.20 |
| 18 | Шәмбе | 22 | 7.34 | 9.24 | 13.30 | 15.44 | 17.31 | 19.21 |
| 19 | Йәкшәмбе | 23 | 7.33 | 9.23 | 13.30 | 15.45 | 17.33 | 19.23 |
| 20 | Дүшәмбе | 24 | 7.32 | 9.22 | 13.30 | 15.47 | 17.35 | 19.24 |
| 21 | Шишәмбе | 25 | 7.31 | 9.20 | 13.30 | 15.49 | 17.37 | 19.26 |
| 22 | Шаршамбы | 26 | 7.30 | 9.19 | 13.30 | 15.51 | 17.39 | 19.28 |
| 23 | Кесе йома | 27 | 7.29 | 9.17 | 13.30 | 15.53 | 17.41 | 19.29 |
| 24 | Йома | 28 | 7.27 | 9.15 | 13.30 | 15.55 | 17.43 | 19.31 |
| 25 | Шәмбе | 29 | 7.26 | 9.14 | 13.30 | 15.57 | 17.45 | 19.33 |
| 26 | Йәкшәмбе | 30 | 7.25 | 9.12 | 13.30 | 15.59 | 17.47 | 19.35 |
| 27 | Дүшәмбе | 31 | 7.23 | 9.10 | 13.30 | 16.00 | 17.49 | 19.36 |
| 28 | Шишәмбе | 1 | 7.22 | 9.09 | 13.30 | 16.02 | 17.51 | 19.38 |
| 29 | Шаршамбы | 2 | 7.20 | 9.07 | 13.30 | 16.04 | 17.53 | 19.40 |
| 30 | Кесе йома | 3 | 7.19 | 9.05 | 13.30 | 16.06 | 17.55 | 19.41 |
| 1 | Йома | 4 | 7.17 | 9.03 | 13.30 | 16.08 | 17.57 | 19.43 |
| 2 | Шәмбе | 5 | 7.16 | 9.01 | 13.30 | 16.10 | 17.59 | 19.45 |
| 3 | Йәкшәмбе | 6 | 7.14 | 8.59 | 13.30 | 16.12 | 18.01 | 19.47 |
| 4 | Дүшәмбе | 7 | 7.12 | 8.57 | 13.30 | 16.14 | 18.03 | 19.49 |
| 5 | Шишәмбе | 8 | 7.11 | 8.55 | 13.30 | 16.16 | 18.05 | 19.50 |
| 6 | Шаршамбы | 9 | 7.09 | 8.53 | 13.30 | 16.18 | 18.07 | 19.52 |
| 7 | Кесе йома | 10 | 7.07 | 8.51 | 13.30 | 16.20 | 18.10 | 19.54 |
| 8 | Йома | 11 | 7.05 | 8.49 | 13.30 | 16.22 | 18.12 | 19.56 |
| 9 | Шәмбе | 12 | 7.03 | 8.47 | 13.30 | 16.24 | 18.14 | 19.58 |
| 10 | Йәкшәмбе | 13 | 7.01 | 8.45 | 13.30 | 16.26 | 18.16 | 20.00 |
| 11 | Дүшәмбе | 14 | 7.00 | 8.43 | 13.30 | 16.28 | 18.18 | 20.02 |
| 12 | Шишәмбе | 15 | 6.58 | 8.41 | 13.30 | 16.29 | 18.20 | 20.03 |
| 13 | Шаршамбы | 16 | 6.56 | 8.39 | 13.30 | 16.31 | 18.22 | 20.05 |
| 14 | Кесе йома | 17 | 6.54 | 8.36 | 13.30 | 16.33 | 18.24 | 20.07 |
| 15 | Йома | 18 | 6.51 | 8.34 | 13.30 | 16.35 | 18.26 | 20.09 |

## ИЗГЕ СҮЗЛӘР

Аллаһ тәннәрен су белән, күңелләрен Коръән белән пакьләүчеләрне сөя.

***(Коръән Кәрим, Тәүбә сүрәсе, 108нче аять).***

Аллаһ тәүбә итеп тәзәлүчеләрне, күңел һәм тән нәҗесләреннән пакьләнүчеләрне сөядер.

**(Коръән Кәрим, Бәкара снрәсе, 222нче аять).**

Чисталык - иманның яртысы.

***(Хәдис шәриф).***

Тәһарәт (чисталык) - намаз ачкычы.

***(Хәдис шәриф).***

Бар көчегезне куеп, чиста, пакь булырга тырышыгыз. Чөнки Аллаһ Ислам динен пакьлеккә нигезләп корган.

***(Хәдис шәриф).***

Аллаһ пакьләнмичә кылган намазны кабул итми.

***(Хәдис шәриф).***

■ Илхам

**Рәфис МУХӘММӘТДИН**
**Янаул шәһәре**

* * *

*"Кара икмәк ашамыйм мин,*
*Яратам агын.*
*Яратам" - ди Гөлсем аның:*
*"Тик яңа чагын".*
*Икмәк сыныкларын җыеп,*
*Чүпкә ташлады.*
*Күзләп торган күрше әби,*
*Җаны әрнүенә түзми,*
*Сөйли башлады:*
*"И балам, телем икмәккә*
*Мохтаҗ чак булды.*
*Ачлык-ялангычлыклардан,*
*Йөзебез сулды.*
*Абзаң яуда, ике балам*
*Ачка шешенде.*
*Каһәр суккан фашист безне,*
*Шуңа төшерде.*
*Ничек түзсен ана җаны,*
*Сорашып чыктым.*
*Барып кердем берәүләргә,*
*Өй эче тып-тын.*
*Өстәл өстендә ак калач,*
*Савытта ит, май.*
*Хуҗа хатын ашый тәмләп,*
*Утырып бик җай.*
*Юри генә дә дәшмәде,*
*Мине табынга.*
*Куып чыгарды, орышып,*
*Бирми кабым да.*
*Кемнәргә генә кермәдем,*
*Шакып ишекләр.*
*Кемнәр генә рәнҗетмәде,*
*Шунда ничекләр.*
*Ә шулай да, күп очрадым,*
*Яхшы кешеләр.*
*Үз авызыннан өзеп бирде,*
*Анаң ишеләр.*
*Ач булсагыз да үзегез,*
*Юмарт иде шул.*
*Ярты капчык арыш онын,*
*Бүлеп бирде ул.*
*Инде балаларым исән,*
*Калмаслар дисәм.*
*Шушы оннан икмәк салып,*
*Калдык без исән!"*
*Ачлык елларын сөйләде,*
*Бу әби һаман.*
*Гөлсем йөзен читкә борды,*
*Оялып аннан!*

### КҮТӘРЕЛӘ МАНАРАЛАР

*Мәсетебез манарасын*
*Кисеп төшергән кемнәр,*
*Көткәннәрме килер диеп,*
*Җилсез-давылсыз көннәр,*

*Адәмнәрнең кулы ничек*
*Күтәрелгән бу эшкә,*
*Әби-бабайлар елаган:*
*"Кермәде дә бит төшкә!"*

*"Ләгънәт суксын динсезләрне!"*
*Мулла кылган догасын. -*
*"Кара йөзләр, имансызлар,*
*Упкыннарга коласын!"*

*Муллаларның теләкләре*
*Кабул булган күрәсең!*
*Әйт кешелек диннән көлеп,*
*Ни рәхәтлек күргәнсең,*

*Күрәм мәчет манарасын*
*Кабат килеп яңарган.*
*Күңелләргә якты иңә!*
*Кабатланмасын кешелек,*
*Булган хатаң яңадан!*

* * *

*Әллә төшем, әллә өнем минем,*
*Нәрсә күрәм, нәрсә ишетәм.*
*Ләх исереп берәү килеп керде*
*Көпә-көндез безнең ишектән.*

*Бу күренеш хәзер гадәти хәл,*
*Диярсездер инде могаен.*
*И сүгенә тозлап һәм борычлап,*
*Егылгандыр тишкән маңгаен.*

*Бу күренеш юк шул, төшем*
*түгел,*
*Мин өнемдә күрәм барсын да.*
*Намазлыкта гына утырасы*
*Карчык басып тора каршымда!*

* * *

*Кеше күңеле ватылырга торган*
*Пыяладай гына шундый юка.*
*Авыр сүзләр әйтеп бер-бербезне*
*Рәнҗетешмик әле зинһар юкка.*

*Бер ягымлы итеп дәшсә кемдер,*
*Җан тулыша сихри рәхәтлеккә.*
*Бер-береңә мәрхәмәтле булу,*
*Илтә безне бары сихәтлеккә.*

*Олыларга олы итеп дәшик,*
*Кечеләргә булыйкчы без кече.*
*Тел байлыгы булу кешелекнең*
*Бәяләнми торган бик зур көче!*

### ЯШИК

*Туу булгач була үлеме дә,*
*Син дә, мин дә берчак китәрбез.*
*Туган җирнең кара туфрагын*
*без,*
*Мәңгелеккә түшәк итәрбез.*

*Мин китәрмен микән синнән*
*алда,*
*Син китәрсең микән, билгесез.*
*Син ничек тә, иркәм,*
*ташлап китмә,*
*Яшәү ямен күрмәм мин синсез.*

*Илһамланып шигырь-җыр*
*язабыз*
*Язмыш авыр, диме, көрәшеп.*
*Мин дә китмим әле шулай*
*бергә*
*Яшик иңне-иңгә терәшеп!*

### КАЗ ӨМӘСЕНДӘ

*Көзге муллык, көзге байлык,*
*Авылда каз өмәсе.*
*Кызлар килә каз йолкырга,*
*Шат күңелле һәммәсе.*

*Кызлар китә каз йолкырга,*
*Балкып тора йөзләре.*
*Кулларына күз иярми,*
*Бигрәк җитез үзләре.*

*И авылым, читкә китеп*
*Югалмасын кызларың.*
*Ямь китмәсен, ел да үссен,*
*Оя-оя казларың!*

